**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**Карамалинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советы башлыгы**

ул. Центральная, д. 8, село Карамалы,
Азнакаевского муниципального района,
423301
Тел. (факс) (855592) 45-6-42

Үзәк урам, 8, Карамалы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423301
Тел. (факс) (85592) 45-6-42

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«23» ноябрь 2021 ел №5

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Карамалы авылы Яшел ур., 1нче йорттан 7нче йортка , Яшьләр ур., 2нче йорттан 58нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2021 елның 07 декабрендэ 11.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Карамалы авылы Төзүчеләр ур., 1нче йорттан 50нче йортка, Профсоюз ур., 2 нче йорттан 31 нче йортка кадэр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2021 елның 07 декабрендэ 13.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Карамалы авылы Үзәк ур., 1 нче йорттан 37 нче йортка, Совет ур., 1 нче йорттан 65 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының оченче этабын 2021 елның 07 декабрендә 15.00 сәгатькә билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Карамалы авылында урамнарны яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампаларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны, электр товарларын сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);
- Җәйге чорда территорияне чаптыру (ГСМ, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Карамалы авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», Халыкара өлкәннәр көне» нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу;
- Карамалы авылында спорт инвентаре һәм җиһазлар сатып алу;
- Карамалы авылы мәдәният йорты бинасында ишек сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. 2021 елда Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге Карамалы авылында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын киләсе эшләрне башкаруга 180 мең сум күләмендә күчерергә килешәсезме?:

1) Карамалы авылы ФАПына су кертү, су бүлү системасын төзекләндерү ( шул исәптән тышкы һәм эчке су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын урнаштыру, сантехник приборлар һәм җиһазлар урнаштыру, су җылыту системасы, шамбо урнаштыру) – 90 мең сум.

2) Карамалы авылы мәдәният йорты бинасында бәдрәф бүлмәсен төзекләндерү (шул исәптән тышкы һәм эчке су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын урнаштыру, сантехник приборлар һәм җиһазлар урнаштыру, су җылыту системасы, шамбо урнаштыру, бүлү һәм ишекләр кую) – 90 мең сум.

6. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Карамалы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.Р. Ногманов